Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«11» ноябрь 2020 ел № 3

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 11 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлегенең Кара Күл авылы торак пункты территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?:

Авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән Кара Күл торак пунктында вак таш салу һәм сезонлы карап тоту» мәсьәләсе белән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 23 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 21 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 21 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Кара Күл авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлегенең Кара Күл авылы торак пункты территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан тыш, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2021 елда 1000 сум сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?:

авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән Кара Күл торак пунктында вак таш салу һәм сезонлы карап тоту» мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кара Күл торак пункты мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Н.В.Авдеева

Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н.В.Авдеева